КӘГАЗЬ ЭШЕ
Җирдә эшләп баеган, табыш алган кеше күренми

> 2

ХАРИС ЗАКИРОВ:
«Журналист һәр сүзенә игътибарлы булырга тиеш»

> 3

ҮЗЕ КИТТЕ
Леонид Слуцкий беренче лигада эшли алмады

> 4

ЯНГЫН СҮНДЕРҮЧЕ:
«Бер-беренә ярдәм итү һәм кешеләрне коткару – иң мөһиме»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 169 (28942) | Чәршәмбе | 16 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

ЮЛ СЫНАТМАСЫН

ДАРУХАНӘЛӘРДӘ ӘЛЕ БЕР, ӘЛЕ ИКЕНЧЕ ДАРУГА КЫТЛЫК БУЛЫП ТОРУНЫҢ СӘБӘБЕ НИДӘ?

Моннан бер ай чамасы элек авылда яшәүче туганым Казан даруханәләреннән «Амоксиклав» дигән антибиотикны эзләп каравымны үтенде. Баксаң, районнардагы барлык даруханәләрдә дә беткән, кайчан кайтачагын да төгәл генә әйтә алмыйлар икән. Белешә торгач, Казанда да бу антибиотикка кытлык икәнлеге ачыкланды. Сезонлы вируслы авырулар котырган чорда барлык даруханәләрдә шушы дару беткән булып чыкты.

pfr.gov.ru

Тагын ике атнадан балабыз авырып киткәч, кабат шул антибиотикны эзләдек. Вазгыять үзгәрмәгән иде. Антибиотикның үзебездә җитештерелгән аналогы белән дәваланырга туры килде.

Ноябрь башында Татарстан Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бу уңайдан рәсми белдерү белән чыкты. Министрлык хәбәреннән аңлашылганча, өлешчә мобилизациянең тәмамлануы, шулай ук базарга яңа җитештерүчеләрнең үтеп керүе сәбәпле, тиздән даруханәләргә препарат китерүдә өзеклекләр бетәчәк. «Якын арада даруханәләрне «Амоксиклав» даруы белән тәэмин итү тәртипкә салыначак», – диелә хәбәрдә. Быел беренче яртыеллыкта Россиядә бу дару барлыгы биш урында җитештерелгән. Хәзерге вакытта Россия складларында якынча 10,5 миллион данә «Амоксиклав» даруы исәпләнә. Бу юлларны язганда без элемтәгә кергән даруханәләрдә препарат әле дә юк иде.

Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгында да бу төр антибиотикка кытлыкны юл мәшәкатьләренә бәйләп аңлаттылар. «Кытлык логистика бозылу аркасында әлеге даруның безгә азрак кертелүе, аңа ихтыяҗның исә зур булуына бәйле. Даруханәләрдә аның аналоглары исә җитәрлек санда», – диделәр «ВТ» хәбәрчесенә министрлыкта.

Даруханәләрдә әле бер, әле икенче даруга кытлык даими рәвештә булып тора анысы. Моңа ияләшеп тә киләбез бугай инде. Әле күптән түгел генә республика халкы даруханәләрдә «Дипроспан» дигән гормональ дару таба алмаудан зарланган иде. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгында якын арада даруханәгә әлеге препарат та кайтачак, дип ышандыралар. «Мәсьәлә хәл ителде. 16 ноябрьдән дистрибьютерлар «Дипроспан» даруын төяп озата башлаячак. Безнең даруханәләргә ул декабрь башында килеп җитәчәк», – дип белдерделәр министрлыкта «ВТ» хәбәрчесенә.

Билгеле булганча, инсульт, инфаркт кичергән кешеләргә дәүләт тарафыннан бушлай дарулар бирелә. Моңа кадәр исемлектә барлыгы 23 препарат исәпләнә иде. Бу көннәрдә Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы карары нигезендә анда тагын 8 төрле дару (ацетазоламид, валсартан + сакубитрил, дапаглифлозин, дигоксин, ивабрадин, спиронолактон, фуросемид, эмпаглифлозин) өстәлде. Әлеге ташламалы бушлай дарулардан ике ел дәвамында файдаланып була.

Россия Дәүләт Думасы депутаты Айрат Фәррахов фикеренчә, даруханәләрдә препаратларга кытлык логистика белән кыенлыклар аркасында гына килеп чыгарга мөмкин. Дару җитештерү мәсьәләсендә тоткарлыклар юк. «Безнең сәнәгать импортка бәйсезлеккә йөз тота. Бүген дару җитештергәндә кулланылган субстанцияләрнең күбесе безгә дустанә мөнәсәбәттә булган Кытай белән Һиндстаннан кертелә. Бу яктан бернинди проблема да юк. Логистика белән кыенлыклар гына килеп чыгарга мөмкин. Ул үзгәрә», – ди депутат.

Казандагы даруханәләр челтәре хуҗасы Гөлия Вәлиәхмәтова да шул фикердә. «Даруларга кытлык булачак дип куркырга кирәкми. Дөрес, аларны кайтартканда тоткарлыклар бар. Бу күбрәк QR-кодлар кертелүгә бәйле. Күмәртәләп сатучы оешма хәзер, товарны алгач, һәркайсының QR-кодын тикшерергә тиеш. Бу – бик күп вакыт таләп итә торган өстәмә эш. Шуңа күрә элек заказ бирелгән дарулар безгә көнендә үк китерелгән булса, хәзер аны бер көннән соң гына алабыз», – ди ул.

Сүз уңаеннан, әле бу көннәрдә генә Казанда Россиядә теркәлмәгән бер төркем даруны юкка чыгардылар. С гепатитыннан дәвалану өчен билгеләнгән әлеге ялган даруларны Татарстанда яшәүче 32 яшьлек ир-ат таратып яткан.

Шуңа күрә интернет аша, кулдан дару сатып алу бик куркыныч, дип кисәтә белгечләр. Росздравнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы Любовь Шәйхетдинова сүзләренә караганда, кулдан дару сатучыларны күзәтеп бетерү кыен.

– Күпләр аны интернет аша сата. Без бу физик затка берничек тә басым ясый алмыйбыз. Андый хокукыбыз юк. Шуңа күрә кулдан дару сатып алыр алдыннан яхшылап уйларга кирәк. Алар дөрес сакланмаган булырга мөмкин. Аның яраклылык вакытын төзәтеп, үзгәртеп тә сата алалар. Шуңа күрә даруны даруханәдән сатып алырга кирәк. Сез аннан теркәлмәгән яки сыйфатсыз даруны берничек тә сатып ала алмыйсыз. Ул бирегә берничә кат тикшерү узып, махсус QR-кодлар ярдәмендә генә кертелә, – ди белгеч.

Якын арада рецепт буенча бирелә торган дарулар да дистанцион рәвештә сатыла башларга мөмкин. Киләсе елның беренче мартыннан моны Россиянең өч төбәгендә – Мәскәүдә, Мәскәү һәм Белгород өлкәләрендә сынап караячаклар. Тәҗрибә өч ел дәвам итәчәк. Әлегә рецептсыз җибәрелә торган даруларны гына онлайн рәвештә сату рөхсәт ителә. Любовь Шәйхетдинова сүзләренә караганда, даруларны өйдә торып кына сатып алу эше коронавирус пәйда булган 2020 елның маенда популярлашкан. Быел бу хезмәттән барлыгы 2,1 мең кеше файдаланган.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Бушка баралар

Россия Хөкүмәте балаларга һәм озатып йөрүчеләренә дәвалану урынына бушлай барып кайтуны күздә тоткан авырулар исемлеген тулыландырган. Бу җәһәттән тиешле карар Министрлар Кабинеты сайтына урнаштырылган. Шулай итеп, киләсе елның 1 гыйнварыннан онкология, кан һәм иммун системасы, бөер авыруларыннан интегүче инвалид балалар өчен дә мондый мөмкинлек ачыла. Моңа кадәр сөяк җелеге чирләре яки җәрәхәтләренә дучар булган, шулай ук Ерак Көнчыгыш төбәкләрендә яки тимер юлларсыз җирләрдә яшәүче инвалид балалар гына дәвалану урынына самолетта бушлай барып кайта алган.

Яшәсен ипотека!

Татарстанда ипотека буенча алыш-бирешләр саны арткан. Росреестрның Татарстан буенча идарәсенең октябрь ае өчен мәгълүматлары шул хакта сөйли. Май – июль айларында ипотека иң аз санда теркәлсә, октябрьдә ике тапкыр артып, 4,5–5 меңнән 9,2 меңгә җиткән. Бигрәк тә торак ипотекасы (май аенда 2,1 мең булса, октябрьдә – 4,6 мең) һәм җир кишәрлеге ипотекасы (майда – 1,4 мең һәм октябрьдә – 2,8 мең) арткан.

Идарә ун ай эчендә барлыгы 78,5 мең ипотека теркәгән. Шуның 37,2 меңе – торак, 1,7 меңе – торак булмаган бина-бүлмәләр һәм 26,1 меңе – җир кишәрлеге ипотекасы. «Татарстанда ипотека базарының җанлануы җәй азагыннан күзәтелеп, хәзер дә дәвам итә. Фатирлар һәм җир кишәрлекләре өчен алынган ипотека саны ике тапкыр артты. Кредит алу нигезендәге алыш-бирешләр саны да ишәйде. Сентябрьдә алар 5 меңнән артыграк булса, октябрьдә инде – 7,5 мең. Үсеш – 45 процент чамасы», – ди идарә башлыгы урынбасары Лилия Борһанова.

Быел күчемсез милек белән алыш-бирешләр саны буенча Казан (15414) һәм Чаллы (5938) беренчелеккә чыккан. Районнар арасында алдынгылар – Түбән Кама (2724), Әлмәт (2407), Питрәч (2382), Яшел Үзән (1991).

Шул ук вакытта гыйнвар – октябрь айларында идарәгә исәпкә кую-теркәү өчен 957 мең гариза кергән. Бу – узган елдагыга караганда 80 меңгә күбрәк.

Кар кыйссасы башлана

«Телеграм»ның «Моя Казань» чат-ботында «Кардан чистарту» дигән яңа категория пәйда булган. Башкалабызда яшәүчеләр, @kznhelpbot чатына кереп, шәһәрнең кардан ничек чистартылуын беләчәк. Димәк, кар көртләре җәяүлеләр яки машиналарга комачауласа, заявка калдырырга мөмкин, дигән сүз. Шәһәр мэриясенең матбугат хезмәте хәбәр иткәнчә, башкалабызда яшәүчеләр чат-ботта гариза темасын сайлый, сорауларга җавап бирә ала. Шуннан соң теге яки бу район буенча гариза булдырылып, шәһәр хакимиятендәгеләр аның үтәлешен күзәтеп торачак. «Урамнар чиратлап чистартыла. Иң элек машиналар һәм җәмәгать транспорты күп йөри торган урамнар кардан арындырылачак, – дип искәртелгән ботта. – Шуннан соң берничә полосалы зур юллар һәм квартал эче юллары, бистә юллары карала».

Актуаль мәсьәлә

Салымны саныйбызмы?

МИЛЕК САЛЫМЫН ТҮЛӘҮ ӨЧЕН ИКЕ АТНА ВАКЫТ БАР

Кышның беренче аена тыныч күңел белән атлыйм дисәң, ике атна вакытыңны салым түләүләрен башкаруга багышла икән. Белгечләр дә эшне озакка сузмаска киңәш итә.

Ул яктан Татарстан халкы тәртипле – ел башыннан республика бюджетына физик затлардан 4,4 млрд сум милек салымы кергән. Россия салым хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе башлыгы Марат Сафиуллин, журналистлар белән очрашып, салым түләү мөһимлеге турында кабат искә төшерде.

Күпме? Марат Сафиуллин әйтүенчә, быел Татарстан халкына салым турында искә төшереп, 2 млн 300 мең «сәлам хаты» җибәрелгән. Салым күләме дә саллы – 8 млрд 700 млн сум. Бу былтыргы күрсәткечтән 7,4 процентка, ягъни 600 млн сумга күбрәк. Чагыштыру өчен: 2020 елда республика халкына барлыгы 7,9 млрд сум салым исәпләнгән, 2021 елда – 8,1 млрд сум. Идарә башлыгы сүзләренчә, салым белдерүләрен җибәрү төгәлләнгән инде.

– Без объектлар һәм субъектлар, күчемсез милек хуҗалары буенча даими рәвештә җитди эш алып барабыз. Җир, фатир һәм транспорт чараларына ия булучылар саны артты, шуңа күрә республиканың берләштерелгән бюджетына керем күләме дә шактый, – диде Марат Сафиуллин.

Салым «хат»ларына, милеккә салым белән беррәттән, исәпләнсә дә, салым агентлары тотып калмаган НДФЛ күләме кертелгән. Быел беренче тапкыр 5 млн сумнан артып киткән керемгә 15 процентлы ставка буенча салым да урын алган.

Кемнәр түли? Искә төшереп китү зыян итмәс: салымны милек ияләре түли. Балигъ булмаган балалар өчен исә салымны ата-аналардан сорыйлар.

– Татарстан халкы милек салымын түләү җәһәтеннән дисциплиналы. Хәзергә 8,7 млрд сумнан 4,4 млрд сум түләнгән инде, – диде Марат Сафиуллин. – Халык «Салым түләүченең шәхси кабинеты» хезмәтеннән актив файдалана. Әйтик, быел 800 мең кеше салым белдерүләрен дә шул хезмәт аша алды һәм салымын да шуның аша башкарды. Башкалар почта аша хатлар алды.

Хат булмаса? Күпләр, бәлки, салым хезмәтеннән «сәлам хаты»н көтеп җиткерә алмагандыр. Шулай да салым түләү мәсьәләсенә битараф карарга ярамый. Нинди очракта килми соң ул салым белдерүләре? Идарә белгечләре берничә очракны телгә алды.

Беренчедән, салым түләүдән тулысынча азат итүче салым ташламасына ия булганнарга хәбәр биреп тормыйлар. Икенче очрак – түләнергә тиешле салымның күләме 100 сумнан азрак булса. Өченчедән, әгәр салым түләүче узган елда арттырып түләгән булса, быел исәпләнгән суммага исәп-хисап ясалып, квитанция килмәскә мөмкин.

Салым түләүгә бәйле сорауларга җавапны рәсми сайтта (**nalog.gov.ru**) һәм Салым федераль хезмәте телефонына (**8800222222**) шалтыратып белергә мөмкин.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Эльвира НӘБИУЛЛИНА, Үзәк банк рәисе:

Микрозаемны кешеләр рәхәт тормыштан алмый. Без моны аңлыйбыз. Микрофинанс оешмаларын тыю турында да фикер алышу булган дип беләм. Безнең уйлавыбызча, аларны тыярга ярамый. Чөнки кешеләр «кара» кредиторлар тозагына эләгергә мөмкин.

(Россия Финанс базары, Салым һәм бюджет комитетларының уртак утырышындагы чыгышыннан)

РОССИЯДӘ – ЭКОЛОГИЯГӘ МӨНӘСӘБӘТ

Россиядә яшәүчеләрнең 84 процентын экологик проблемалар борчый икән. Бу хакта аналитиклар оештырган сораштыру нәтиҗәләре сөйли.

НӘРСӘ БОРЧЫЙ?

- **56%** >> су һәм һаваның пычрануы
- **14%** >> урманнарны кисү
- **13%** >> климат үзгәреше
- **7%** >> кайбер хайваннарның юкка чыгуы

Айбашта азан өзелмәс

Биектау районы Айбаш авылындагы мәчетне (шушы көннәрдә көчле җилдән манарасы ауган) торгызуга ике ел чамасы вакыт кирәк булачак. Корылманың күпчелек өлеше – авария хәлендә. Түбәсен тулысынча алыштыру, манарасын яңадан төзү таләп ителә. Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин әйтүенчә, агач мәчет инде моңа кадәр дә төзекләндерүгә мохтаҗ булган. Хәзер дин тотучыларның намазга кая йөрисе хәл ителә. «Әмма бу авылда намаз уку туктатылмаячак», – дигән ул.

Мәчет инде XIX гасырда ук төзелгән. Ул агачтан эшләнгән тиңдәшсез ядкәр булып тора. Соңгы тапкыр 1998 елда түбәсе алыштырылган.

Җәен дин тотучыларга уңайлы вагон яки чатыр булдырылачак. Җирле хәзрәт Дамир Хәбибуллин үз өендә дә намаз укытырга әзер.

mchs.tatarstan.ru



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СӨЙЛӘШМИЧӘ БУЛМЫЙ

Мәгълүмат кырына моннан берничә көн элек Көнбатыш дәүләтләре тарафыннан Россиягә Украина конфликтын туктату турында җитди тәкъдим ясалу турында хәбәрләр таралган иде. Рәсми яңгыраш тапмаганга күрә, сәхнә арты мәгълүматын без китерә алмыйбыз. Әмма ул мәгълүмат дөрес булса, хәрби хәрәкәтләр өстәл янында кул кысышып тәмамлана алыр иде.

Ләкин әлегә Мәскәүдә дә, Киевта да килешүгә нык каршы көчләр бар. Дәүләт Думасы вице-спикеры Толстой: «Тыныч сөйләшүләр турында хыялланучыларның күңелен төшерергә телим: андый нәрсә булмаячак», – диде. Контексттан аергач, бик аңлашылып бетми, шуңа күрә искәртәбез: депутат Киев куйган шартларда сөйләшүләргә каршы. Тышкы эшләр министрлыгының рәсми вәкилләре дә нәкъ шуны җиткерә: сөйләшүләр кире кагылмый, каршы як куйган таләпләргә буйсынып очрашу гына кире кагыла. Киевта да шундый ук хәл: Мәскәү файдасына сөйләшүләрне кире каккан белдерүләр яңгырый, хәтта АКШ генералы Марк Миллиның якларны «сугыш кырында җиңәргә» өметләнмәскә, тынычлык урнаштыруның башка чараларын эзләргә чакыруы да Украина хәрбиләренең җен ачуын чыгарды.

Шулай да утсыз төтен чыкмый. Боз астында су акмый калмый ул. «Российская газета» үзенең телеграм-каналында: «АКШның Дәүләт департаменты Мәскәү һәм Киев арасында булачак сөйләшүләргә нигез әзерли», – дигән хәбәр бар. Менә шул хәбәр булмаса, газета хәбәрчесе бу юлларны язарга алынмас та иде. Безнең кулда ике яклы килешүнең проектына кадәр бар, әмма аны мәгълүмат кырына чыгарып булмый. Теләсә нинди хәбәр фейк дип бәяләнә ала, ә фейклар өчен җәза каты. Федераль хөкүмәт органы Вашингтонның бу мәсьәләдә Киев белән даими консультацияләр алып баруы һәм килешүне Украина мәнфәгатьләрен нык истә тотып әзерләве хакында әйтә.

Дүшәмбе көнне АКШ һәм Россия разведкалары җитәкчеләре Әнкарада Милли төрек разведка оешмасының штаб-квартирасында очраштылар да инде. «Очрашуның детальләре игълан ителми, ләкин алар РФ һәм АКШ арасында элемтәләрне җайга салу өчен әһәмияткә ия», – дип белдерә төрекләрнең NTV телеканалы. «Рейтер» агентлыгы исә: «Әнкарадагы сөйләшүләрдә Украинадагы конфликтны көйләү тикшерелде. Үзәк разведка идарәсе директоры Уильям Бернс Нарышкинга атом-төш коралы куллануның нәтиҗәләре нинди булачагын әйтте һәм Россиядә кулга алынган Америка гражданнары мәсьәләсен күтәрде», – дигән хәбәр таратты. Рәсми мәгълүмат кырына исә Россия төрмәсендәге АКШ гражданнарын Россиянең Америка төрмәсендәге гражданнарына алмашу турында фикерләшүләре турында хәбәрләр генә чыгарылды.

Барлык конфликтларның да сөйләшүләр өстәлендә төгәлләнүен искә алганда, хәрәкәт башланган икән, аны хупларга гына кала. Әмма әлегә ике илдә дә вазгыять бик кискен булып кала бирә.

Россиядә

БАРЫСЫ ДА ШУЛ ХАКТА

Атна башында Россия белән бәйле ике зур дөньякүләм вакыйга булып узды. Беренчесе: G20 саммиты кысасында Россия – Украина конфликтын туктатырга чакыру яңгырады.

Дөньяның иң зур икътисадына ия булган егерме илнең күпчелеге конфликтта Россияне гаепли һәм хәрби хәрәкәтләрне туктатырга чакыра. Индонезия Президенты Джоко Видодо очрашуны ачып җибәргәндә үк: «Без сугышны туктатырга тиеш», – дип әйтте. «Российская газета» сайты, аның сүзләрен китереп: «Шуның белән бергә ул кайсы хәрби конфликтны әйтүен ачыкламады», – дип язды. Әмма «РИА Новости» тараткан рәсми мәгълүмат G20гә кергән күпчелек илләрнең Россиянең Украинадагы хәрәкәтләрен гаепләүләре турында уртак белдерү кабул иткәнен раслый. Мәскәү дипломатик фронтта һәм мәгълүмат кырында нык оттыра, моны танырга кирәк.

Саммит ачылыр алдыннан Байден белән Си Цзиньпинның планлаштырылган очрашуы булды. Яклар ике арадагы мөнәсәбәтләрне генә тикшереп калмады, билгеле. Өч сәгатьтән арткан сөйләшүдә алар Украинада атом бомбасы куллану белән янаучыларны гаепләделәр. Байден Кытайны Төньяк Кореяны җиденче атом-төш сынауларын үткәрмәскә үгетләргә дә өндәде. Ике як та Россиянең көнбатыш чикләрендәге конфликтны туктату ягында булуларын белдерде. Очрашудан соң Байден журналистларга: «Без бер-беребезне аңлыйбыз дип уйлыйм», – диде. АКШ – Кытай диалогы дәвам итәчәк. Американың дәүләт секретаре Энтони Блинкен, сөйләшүләрне дәвам иттерер өчен, Пекинга барачак.

Ике держава арасындагы диалог сөендерә, әлбәттә. Ракеталар теле белән сөйләшүгә караганда, дипломатик телдә аралашу яхшырак. Әмма: «Дипломатия ул – әңгәмәдәшеңне шайтанга олактырганда, ул сәяхәткә җыена башларлык итеп олактыру осталыгы», – дигән сүзләр дә бар. Си һәм Байден очрашуы хакында сөйләгәндә дә без моны истә тотарга тиешбез.

Мәскәү өчен тагын бер уңайсыз хәл Берләшкән милләтләр оешмасы (БМО) Генераль ассамблеясында булды. Ассамблея Украинага Россия тарафыннан репарацияләр турында резолюция кабул итте. Резолюциягә Мәскәүнең традицион аркадашлары булган берничә ил генә каршы тавыш бирде. Алар арасында Кытай, Төньяк Корея, Белоруссия, Иран, Зимбабве, Нигерия кебек илләр бар. Кытайдан башкалары дөньякүләм мәйданда көчле йогынтыга ия түгел. Бер нәрсәне яхшы белергә кирәк: резолюция ниндидер юридик көчкә ия түгел, әмма шуңа таянып, аерым дәүләтләр яисә дәүләтләр төркеме Россиянең бикләнгән активларын Украина файдасына куллану турында карарлар кабул итә ала. Резолюциядә исә Россияне халыкара хокукны бозган өчен җавапка тарту турында да сүзләр бар. БМО резолюциясенә таянып, аерым дәүләтләр Россия акчасын тота башласалар, каршылыклар артачак кына. Шуңа күрә ашыгып тотынмаслар дип уйлыйк. Конфликтка кергән якларның мәсьәләне өстәл янында сөйләшеп хәл итүләре уңайрак. Мәскәү, хәрби операция төгәлләнгәннән соң, җимерекләрне торгызуга каршы түгел бит. Дөрес, юридик нечкәлекләр бар инде анда, әмма аларны дипломатик юл белән хәл итү яхшырак.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

КИЛӘЧӘККӘ КАРАП

Ил икътисадының технологик яктан бәйлелегеннән уртак тырышлык ярдәмендә генә котылып була. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Президент каршындагы Мәгариф һәм фән советының чираттагы утырышында шулай дип белдерде.

Республика җитәкчесе фикеренчә, Татарстанда бу максатны чынга ашыру өчен бөтен шартлар да бар. «Республикадагы югары уку йортлары белән фәнни оешмалар «Фән һәм университетлар» илкүләм проектының һәм башка технологик үсеш инициативаларының барлык төп чараларында тәкъдим ителгән. Республикада мәктәптән башлап өзлексез белем бирү чылбыры буенча тикшеренү һәм инженерлык юнәлешләрен формалаштыруның тулы бер системасы булдырыла», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул Татарстанда фәнни тикшеренү нәтиҗәләрен тормышта кулланырга мөмкинлек биргән 2 махсус икътисади зона, 5 ТОСЭР, 8 технопарк, Инновация һәм эшкуарлык эшчәнлегенә ярдәм фонды барлыгын да искәртте. Быел алар сафына КФУ базасында оештырылган югары уку йорты стартап-студиясе дә өстәлгән.

Әмма фән-мәгариф тармагында ирешелгән уңышлар белән беррәттән проблемалар да саклана бирә. «Татарстанда фәнни кадрлар сафы 1990 елларда шактый кимеде. 1992 елда республиканың фән-технология өлкәсендә эшләүчеләр саны 30 меңнән артып киткән. Бүген алар 13 меңнән дә азрак, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Бөтен ил күләмендәге фән-мәгариф тармагына хас проблема бу. Киләчәккә карап эш итмичә торып, аларны хәл итү нәтиҗәле булмаячак. Шул сәбәпле, быел Татарстанда төп игътибар төбәкнең фәнни-технологик үсеш стратегиясен һәм программасын әзерләүгә юнәлдерелгән иде».

Цифрлы үсешкә ярдәм итү ассоциациясе советы рәисе Рифкать Миңнеханов бу хакта тәфсилләбрәк сөйләде. Аның чыгышыннан аңлашылганча, фәнни-технологик үсеш стратегиясен һәм программасын әзерләгәндә, республиканың федераль һәм халыкара дәрәҗәләрдә танылган 15 терәк фәнни мәктәбенең мөмкинлекләренә зур игътибар бирелгән. Татарстанның көндәшлеккә сәләтле өстенлекләре дә ачыкланган.

Авторлар коллективы җитәкчесе, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәге директоры Марат Сафиуллин сүзләренә караганда, фәнни-технологик үсеш программасының төп максатлары Татарстанда табигать фәннәре буенча белем бирүне үстерү; фәнне, шулай ук республика проектларын һәм технологияләрен популярлаштыру, алга җибәрү; инновацион ваучерлар кертү, икътисадның яңа тармакларын үстерү өчен шартлар тудырудан һ.б. гыйбарәт.

Рөстәм Миңнеханов белдерүенчә, Россия Президенты карары белән 2022–2031 еллар Россиядә фән һәм технологияләр унъеллыгы дип игълан ителгән. «Безнең республика, фәнни-технологик үсешнең күп кенә күрсәткечләре буенча алдынгы буларак, дәүләт башлыгының бу башлангычында актив катнашачак», – диде Президент. Рөстәм Миңнеханов Татарстанда Республика Координация советы булдырылуын да искәртте. Аның төп бурычы фән һәм технологияләр унъеллыгын уздыру буенча республика чаралары планын тормышка ашырудан гыйбарәт.

Утырышта катнашучыларны әлеге план проекты белән Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин таныштырды. Проект 37 пункттан тора. Бу чаралар төп өч бурычны хәл итүгә: яшьләрне фәнгә җәлеп итү, тикшеренүчеләрне ил үсеше бурычларын хәл итүгә катнаштыру, шулай ук Россия фәне турындагы мәгълүматның халык өчен ачык булуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Икенче укылышка әзер

2023 елга һәм пландагы 2024–2025 елларга республика бюджеты турында закон проекты икенче укылышка әзер. Дәүләт Советының Бюджет, салым һәм финанс комитеты белән комитет каршындагы Экспертлар советы уртак утырышында депутатлар, Хөкүмәт тәкъдим иткән төзәтмәләр каралды. Аларның бер өлеше төшереп калдырылды, башкалары тәкъдим ителде.

Бюджет, салым һәм финанс комитеты рәисе Леонид Якунин бюджет турында закон проектына икенче укылышка 701 төзәтмә алынуын, шуның 660ы – Министрлар Кабинетыннан, 24е – Дәүләт Советы депутатларыннан,17се комитеттан керүен әйтте. «Депутатлар керткән төзәтмәләрнең барысы да комитет утырышына кадәр җентекләп эшләнде, шул сәбәпле алар төшереп калдырылды», – диде комитет башлыгы.

Нәтиҗәдә 677 төзәтмә карап тикшерүгә чыгарылган. Алар асылда федераль үзәктән өстәмә акча бирелү ягыннан бюджетны аныклауга юнәлдерелгән. Федераль бюджеттан алынучы барлык акча – максатчан. Күбесе республика бюджетыннан да өстәүне таләп итә.

Финанс министры Радик Гайзатуллин билгеләп үткәнчә, үзгәрешләр 80 юнәлешкә кагыла. 2023 елда федераль акча күләме, 9,9 миллиард сумга артып, 61,8 миллиард сумга җитәчәк. Киләсе елда дәүләт программаларын тормышка ашыруга республика бюджетыннан 1,9 миллиард сум өстәп биреләчәк.

Кертелүче үзгәрешләр нәтиҗәсендә 2023 елга республика бюджетының гомуми кереме күләме 343 миллиард 773,2 миллион сум, чыгымнар – 370 миллиард 920,7 миллион сум тәшкил итәчәк. Бюджет дефициты элеккечә калачак.

Профильле комитет әгъзалары Дәүләт Думасы депутатларының 2023–2025 елларга федераль бюджет проектын икенче укылышта тикшерү өчен әзерләгән төзәтмәләрен дә карады. Татарстанга федераль средстволарның киләсе елда – 160 миллион 473,5 мең сум, 2024 елда – 123 миллион 329,1 мең сум, 2025 елда 116 миллион 823,1 мең сум күләмендә өстәмә рәвештә җибәреләчәген исәпкә алырга кирәк. Биредә сүз кайбер категориядәге кешеләргә социаль контракт нигезендә дәүләт ярдәме күрсәтүгә һәм авыл территорияләрен үстерүгә субсидияләр турында бара.

Бу программалар акчаны республика бюджетыннан да өстәп бирүне таләп итә.

Республика бюджеты белән бер үк вакытта Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты да карала. Бу җәһәттән закон проекты да икенче укылышка әзерләнгән. Аңа 10 төзәтмә алынган.

Комитет утырышында быел 9 айда республика бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын үтәү турында мәсьәләләр каралды. «Керемнәр динамикасы узган елдагы белән, шулай ук фараздагы күрсәткечләр белән чагыштырганда да уңай, – дип басым ясап әйтте Радик Гайзатуллин. – Алар барлык социаль йөкләмәләрне тулы күләмендә үтәү, планлаштырылган чыгымнарны финанслау мөмкинлеге бирде».

САЛЫМНЫ САНЫЙБЫЗМЫ?

nalog.gov.ru

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бу очракларның берсе дә туры килмәсә, нишләргә? Кичекмәстән салым инспекциясенә яисә күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә. Сүз уңаеннан, мәсьәләне өйдән чыкмыйча гына да хәл итәргә мөмкинлек бар. Физик затка «Налоги ФЛ» мобиль кушымтасын кулланырга киңәш итәләр. Моннан тыш Салым федераль хезмәтендәге «шәхси кабинет» аша да салым түләүләрен башкарырга мөмкин.

Мобилизацияләнгәннәр нишли? Түли, билгеле. Әмма соңрак. Марат Сафиуллин әйтүенчә, өлешчә мобилизация кысасында хәрби хезмәткә чакырылганнар өчен таләпләр башка.

– Мобилизацияләнүчеләр өчен яңа түләү срогы белән башка салым белдерүләре җибәреләчәк. Салымны хәрби хезмәттән азат ителгәннән соң өч ай узгач, ярты ел эчендә түләргә кирәк булачак, – дип аңлатты идарә башлыгы.

Моңа өстәп, мобилизацияләнгәннәр транспорт салымыннан азат ителә.

Алдынгылар. Салым түләү буенча авылларга тиңнәр юк, ди. Вакытында түли сала халкы. Лидерлар дип Түбән Кама, Чистай, Алексеевскины атарга була тагын. Ә менә Лаеш районы – түбәндә. Салым җыясы объектларның анда шактый булуын әйтә идарә белгечләре дә.

Озын сүзнең кыскасы, салым түләмичә, бу эшне озакка сузып йөрисе түгел. Аның бит әле җәзасы да бар. Берне бирмим дип, бишләтә чыгарырлык булмасын иде.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

АВЫРТКАН ҖИРДӘН КУЛ КИТМИ

ҖИР ТАБЫШ КИТЕРӘМЕ?

Мөнәсәбәт

Өстәгеләр, авыл кешесе җирдән күп итеп табыш ала дип чын-чыннан ышана, ахрысы. Соңгы елларда кабул ителгән җиргә бәйле кануннар барысы да шул хакта искәртә. Катлаулылыгы да, мәшәкате дә. Шәһәрдәгеләр дә шулай ышана, пай җирләрегезне сата күрмәгез, җир ул – байлык, дип киңәш бирүчеләр, акыл сатучылар да очрап тора.

Тик авылда яшәүчеләр генә моның хакыйкатьтән бик ерак торуын аңлый. Күз алдыбызда шул: кызганыч, җирдә эшләп баеган, табыш алган кеше күренми. Сүз йөзләрчә гектарлар турында түгел, фәлән сутый җирдә генә эшләп, печән, бәрәңге үстерүчеләр турында. Күбебез шуны аңлаганга, соңгы елларда авылларда җирләрен арттырырга теләүчеләр күренми дә диярлек.

Әнә авылдашым Гөлия үткән ел: «Үзебез аз гына өлешенә бәрәңге утыртабыз, калган өлешенә һич югы печән чәчәргә теләүче булмасмы икән?» – дип, авыл буенча кеше эзләп йөрде. Күпме кешегә әйттем, алам дигән кеше юк дигәне истә (ахыр чиктә тапты үзе). Моннан егерме-утыз еллап элек, хуҗалык рәисе алышынгач, барыбыз да, биргәндә алыйк әле дип, читтән өстәмә кем ун, кем унбиш-егерме сутый җир алган, ничә еллар бәрәңге утырткач, аннан печән җирләренә әйләндергән идек. Ул җирләрдән беркайчан табыш алмадык. Хәзер инде бигрәк тә. Бер мең сумга бер рулон печәнеңне сатып алсаң, өеңә китереп бирәләр – эшең дә, хәсрәтең дә бетте. Бер рулонлык печәнне ул бакчадан җыю өчен күпме мәшәкатьләнергә, күпме чыгым түгәргә кирәк. Эшен, чыгымын уйламас идең, эшләргә кешең булу да кирәк. Өстәвенә, печәнне чаптыртуга, гадәттә яңгырлар башлана яки кибеп бетте дигәндә яңгыр явып, эшне боза… Кыскасы, аның инде табыш чыганагы булмавын күптән аңладык. Күбебез хәзер ташларга җәлләп кенә куллана. Тик…

Җәй азагы иде. Росреестрдан (Дәүләт регистрация, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Кукмарадагы районара оешмасыннан) кисәтү хаты килде. Аннан күренгәнчә, 2016 елда унөч сутыйдан артыграк җиргә өч елга килешү төзегән

Чулпан Гарифуллина

булганбыз, өч ел элек срогы чыккан! Һәм зур кара хәрефләр белән, бу хәлне төзәтмәсәк, җир турындагы канун нигезендә нинди чаралар күреләчәге турында кисәтү язылган. Әлеге хатны тотып, районның Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы – ПИЗОга киттем. Исәбем җирдән баш тарту иде. Бүлек җитәкчесе – авылдашым Ильвир Фәтхетдинов әлеге эшнең тәртибен аңлатты да: «Гөлсинә апай, әлегә печәнен чабасыз бит, барыбер артыннан йөрисез, хәзергә ташламагыз», – дип киңәш бирде. Ташлый башлагач, нәрсәгәдер җәлләтә башлаган иде инде, риза булдым. Һәм бераздан инде: «Белгән булсам…» – дип ничә кат үкендем.

Әлеге җир әни исемендә булганлыктан, башта аның исеменнән башкарма комитетка килешүне өзү турында гариза язарга туры килде. Аннан, башкарма комитеттан рөхсәт булгач, үз исемемнән бу җирне алырга гариза язасы, аннан рөхсәт булгач, килешү төзисе, банкка кереп, башта теге еллар өчен җыйналган әҗәтне, аннан яңа килешүдә күрсәтелгән өч ел өчен түләргә, әле арасында МФЦга барып, нәрсәдер язарга, тутырырга кирәк булып чыкты, аннан тагын ПИЗОга… Аларның һәркайсы арасында күпмедер вакыт үтә. Берьюлы бөтенесен дә эшләп булмый, һәрберсенең – үз чираты, үз тәртибе… Район үзәгенә ничә тапкыр барып кайтырга кирәклеген чамалагансыздыр. Гөнаһ шомлыгына, инде бу җир документлары белән эш бетте дигәндә, кисәтүнең бер генә җир участогына килгәнен аңладым… Ике участок күптән бергә кушылса да, документта алар аерым йөри иде. Ике меңенче еллар тирәсендә Шушма елгасы буендагы җирләребезгә бәрәңге утыртырга ярамый дигәч, унөч сутыйлысы янәшәсенә күчертелгән алты сутыйдан артык җир дә бар иде. Элекке килешүне ике җир өчен бер документта төзегән булсалар да, ни сәбәпледер, бу җир аерылып калган, аңа кисәтү килмәгән булып чыкты.

Кайчан да булса барыбер килеп чыгар дип, Росреестердан белешкән идем, анда да мең сумнан артык әҗәт җыйналган булып чыкты. Кыскасы, кабат шул ук этапларны үтәсе булды. Инде соңгы тапкыр ПИЗОга гына барасы калды. Хәзер өч ел буе курыкмыйча, егерме сутый җирдән, аяк тибеп, табыш ала алам. Шөкер, Росреестрның районара бүлегендә эшләүче кызлар да, МФЦдагылары да бик ярдәмчел, кешелекле. Тәртибен дә әйбәтләп аңлаталар, булышырга әзер дә торалар. Кешеләр белән эшләгәндә монысы бик мөһим. Бу катлаулы процессны ырып-ерып чыгар өчен, мондый ярдәмчеләр бик кирәк.

Ни өчен бу хакта шушылай иркенләп яздыммы? Иң элек, тиешле органнардан авыл кешесенә «җиргә аренда килешүегезнең срогы бетә» ише берәр кисәтү хаты җибәрү отышлы булыр иде. Ышанам, минем кебек, килешү төзегәнен дә онытучылар авылда шактый. Салым органнары ел да җибәргәч, алуга, түләргә тырыша бит күбебез (сүз уңаеннан, быел алар да шактый кешегә хатлар җибәрмәде, шәхси кабинетларда да мәгълүмат күренмәде, салымнарны эзләп алырга туры килде. Бу эш тагын җайга салынса, салым түләүдә өзеклекләр дә кимер иде).

Икенчедән, авыл кешесе, әй, бу җирнең кирәге калмады инде дип, читтәге бакчаларын үз белдеге белән ташламасын иде дип кисәтүем. Беркөнне чүп үсеп утырган җирләрегезгә зур күләмдәге түләүләр, штрафлар килергә мөмкин. Җир кодексының әллә ничә статьясын бозучы буларак, җавапка тартырга да мөмкиннәр.

…Үзем дә өч ел үткәннән соң әлеге килешү турында ничек тә онытмаска кирәк дип, хәтеремә беркеткән булдым инде. Гаризаны язып, канунына туры китереп ташларга кирәк булыр…

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

ВЕТЕРАН ЖУРНАЛИСТ ХАРИС ЗАКИРОВ:

«ҺӘР СҮЗГӘ ИГЪТИБАР БИРЕЛӘ ИДЕ»

Безнекеләр

40 елга якын гомерен журналистикага багышлаган, дистә елдан артык газетабызда хезмәт куйган Харис абый Закиров шушы көннәрдә 80 яшьлек күркәм юбилеен билгеләп узды. «Ватаным Татарстан»ның юбилей елы алдыннан ветеран журналистыбыз белән очрашып, тарих сәхифәләрен барладык.

Харис абый Закиров – тумышы белән Әгерҗе районының Иске Акхуҗа авылыннан. Башта Казан авыл хуҗалыгы техникумын, соңыннан Казан дәүләт университетын тәмамлый. Һәм 40 ел гомерен татар журналистикасына хезмәт итүгә багышлый. 1998 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеменә, 2002 елда «Мәгарифтәге казанышлар өчен» күкрәк билгесенә ия була.

«Социалистик Татарстан»да («Ватаным Татарстан»ның ул чактагы атамасы. – **Авт.**) 11 ел буе – 1991 елга кадәр хезмәт куя ул. Без, яшьләргә, ветеран журналистларыбыз белән очрашып сөйләшү – үзе бер җаваплылык. Харис абый белән безнең арада берничә буын журналистның каләме сыналган бит. Ул эшләгән елларда газета тормышы һәм гомумән, журналистика нинди булган? Сөйләшүебезне журналистика тарихының кайбер сәхифәләрен барлаудан башладык.

– Ул чакта журналистларның абруе бик зур иде. Хәтта бездән куркып тордылар. Теге яисә бу районга командировкага барып төшәсең дә хуҗалыклар буенча йөреп кайтасың бит инде. Аннан шул хуҗалыклар, нәрсә язды икән, дип көтеп торалар иде, – дип искә алды Харис абый. – Ә журналист, үз чиратында, һәр сүзен үлчәп, аның дөреслеккә туры килү-килмәвен тикшереп язарга тиеш була. Ул яктан мин үземә бик таләпчән идем. Алынган тема һәм проблемамны «җырмачлап» өйрәндем, «Социалистик Татарстан»да эшләгән елларымда да, аннан соң да мин язганнарга ризасызлык белдермәделәр. Ул чакта журналист һәр сүзенә игътибар бирә иде. Бүгенге буын журналистларына үзләренә карата менә шушы таләпчәнлек җитми.

Үзе исә журналист булып эшли башлаганчы, беренче белеме буенча хезмәт куя. «Социалистик Татарстан»га алып килгән юллары да бераз бормалы була. Студент чагында ук каләм чарлап, үзен өметле журналист итеп күрсәтергә өлгерсә дә, ул чакта татар газеталарының редакцияләрендә урын булмый. Яшь Харисны да кире боралар. Ул чакны: «Социалистик Татарстан»да урын булмагач, журналист булу уемнан кире кайта яздым, бераз үкенеп куйдым», – дип искә ала әңгәмәдәшем.

Ләкин бирешми: тота да Уфа каласына чыгып китә. Андагы «Кызыл таң» газетасына эшкә урнашып карый. Сөйләшә торгач, авыл хуҗалыгы бүлегенә эшкә алалар. Биш-алты районның үзхәбәрчесе була Харис абый.

Ләкин Уфада озак тормый. «Кызыл таң»ның баш мөхәрриренә: «Өйләнәсе иде бит. Ә өйләнәсе кешемнең монда киләсе килми», – дигән була да туган ягына кайтып китә.

Берникадәр вакыттан Журналистлар берлегендә күзәтүче булып эшли башлый. Көн саен «Социалистик Татарстан»га күзәтү ясый. Ә бераздан шушы газетада эшли дә башлый.

– Мин ул чакта ук хикәяләр язгалый идем. Шуларның берсен баш мөхәрриребез Шәмси Хамматов күреп алган. Шуннан: «Әйдә, безгә эшкә кил. Мораль темасына язарсың», – дип чакырып алды. Хатлар, спорт, партия тормышы бүлекләре һәм тагын берничә бүлек өчен җаваплы булдым. Ул чакта газетаның тиражы 200 меңгә җитте. Халык матбугатны бик күпләп укый иде, – дип сөйли Харис абый.

Тора-бара мәкаләләрендәге геройлар, тема һәм проблемалар аның әдәби эшчәнлегенә күчә. Ул бер-бер артлы хикәя һәм повестьлар иҗат итә башлый. Хәзер инде Харис абыйның иҗат җимешләре тупланган «Керпе мыегы», «Әрәмәдә карама» кебек берничә җыентык-китабы бар. Ул – Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 60 ел тулу уңаеннан бастырылган «Арчалылар – Бөек Ватан сугышында» дигән ике томлык хезмәт авторы да. Монысын пенсия ялына чыккач башкарып чыга. Һәр ветеранның өендә булып, орден-медальләрен, истәлекле хатларын, хатирәләрен барлап йөри.

Әле кичә генә Харис абый 80 яшьлек матур юбилеен билгеләп узды. Бүген дә иҗат итүдән туктамый ул. Узган ел ахырында гына тагын бер җыентык бастырган. Озак яшәүнең, өлкән яшьтә дә актив иҗат итүнең серен сорамый булдыра алмадык.

– «Генетик фон» дигән нәрсә бар. Мин олы яшькә җитүемне шуннан күрәм. Әле бит минем 1936 елгы абыем да исән-сау. Аннан соң, үземә команда биреп, урамда йөреп керергә, хәрәкәтләнергә тырышам. Хәер, хәзер барыбер яшь чак түгел инде…

Без исә ветеран журналистыбыз Харис абый Закировка иҗат итеп яшәргә исәнлек-саулык, озын гомер телибез!

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БАБАЙ ТҮГЕЛ, КӘТТӘ ЕГЕТ БУ

Автор фотосы

Туган ил буйлап

18 ноябрь – Кыш бабайның туган көне. Әлбәттә инде, монда Кырлайдагы Кыш бабай турында түгел, Великий Устюгтагы Дед Мороз турында сүз бара. Датасы да очраклы гына сайланмаган. Беренче кышкы салкыннар нәкъ менә 18 ноябрьдә Великий Устюгта башлана дип исәплиләр.

Балалар белән кышкы каникулда ял итәргә менә дигән урын ул. Табигатькә якын булу, тарихны барлау үзе үк – файдалы гамәл. Шунысы кызык: Кыш бабай янында балаларның өлкәнрәкләре дә могҗизага ышана башлый. Хәтта тора-бара үзебез дә шул халәткә керәбез.

Морок карттан – Морозга

Көнчыгыш славяннарда зәмһәрир салкыннар алып килүче картны Морок дип атаганнар. Картлачның холкын озак еллар күзәтеп барганнан соң, мәҗүси халык бер нәтиҗә ясаган: әгәр кыш салкын һәм карлы килсә, җәен уңыш мулдан булачак икән. Шуңа күрә алар, төрле тәм-томнар әзерләп, Морокны үзләренә дәшә башлаганнар. Ниһаять, тылсымчыны яратканнар һәм өстендәге кафтанын – тунга, аягындагы чабатасын итеккә алыштырганнар.

Борынгы Русь Морокны оныткан. Бары XIX гасыр башында гына, Александр II нең балаларын Яңа ел һәм Рождество белән котлау өчен, акыл иясе уйлап табылган. Киң күңелле, мул куллы бу карт, өйдән-өйгә йөреп, балаларга күпме генә бүләк-күчтәнәчләр өләшеп йөрсә дә, халык аны үзенеке итеп кабул итмәгән. Ә гасыр ахырында Изге картны хәзерге шаян-шук Кыш бабай алыштырган. Тик ул бик озын гомерле булып чыкмаган. Православие диненең бер атрибуты буларак, 1929 елда халык тормышыннан сызып ташланган. Ләкин балаларны бәйрәмнән мәхрүм итүнең дөрес булмавына төшенеп, җиде елдан Сталин аңа кабат җан өргән.

Шундый озын юл үтүенә карамастан, хәзерге заман Кыш бабае барлыкка килгәнгә 23 ел гына әле. 1999 елда куе урманнар эчендә утырган Великий Устюг аның төп биләмәсе булырга лаек дип табылган. Россиядә Яңа елны каршы алу Кыш бабайның, Кар кызын янына алып, иксез-чиксез илебезнең төрле шәһәрләренә сәфәр чыгуы белән башланып китә. Башкалабыз Казанга да килә ул. Кыш бабайның статусы бик югары. Аның сарае 12 бүлмәдән тора. Нәкъ елдагы айлар санынча. Һәр бүлмәнең – үз тылсымы. Тик анда керү өчен, төрле сынаулар узарга кирәк.

Әкиятләр сукмагы

Әкиятләр сукмагында беренче булып шат күңелле Убырлы карчык каршылый. Аның берничә мәкерле табышмагына җавап бирмичә торып, алга таба үтү мөмкин түгел. Тапкырлык күрсәтеп, барлык сорауларына җавап биргәннәр генә тылсымлы кое янына җитә ала. Анда исә җыр-бию белән, шамакайланып, һәр кешене сәвәләйләр чолгап ала. Алар белән тыпырдыйсың да җылынасың! Аннан соң кое төбенә карап, иң зур теләгеңне әйтсәң дә була. Үтәләчәк!

Бу сынаудан соң Михайло Потапович күперен узмыйча булмый. Кыш бабайның тавышы өндәп тора: «Кем дә кем Бәхет күпере аша уза, шул ел буе бәхетле була!» Аю артыннан тыпырдап, кулыңны чәбәкләп үтәргә кирәк бу «сират күпере»н. Менә шуннан ары балалар өчен иң кызыклы урынга – Могҗизалар аланына килеп чыгасың инде. Монда куркак куян, үзенең бер дә куркак булмавын раслап, балаларны баһадирлыкта һәм җитезлектә сынап карый һәм җиңүчеләрне күркәбол уенына чакыра. Күркәләрне мишеньгә ату белән мавыккан балалар гына түгел, өлкәннәр дә дөньяларын онытып җибәрә. Аушка кортка өенә кереп, галәмәт зур мич янында җылына-җылына төрле дару үләннәре турында хикәятләр тыңлау, Унике ай учагын уратып, әйлән-бәйлән уйнау, тылсымлы сандык катында музыкаль концерт тыңлау – болар барысы да балаларны Кыш бабай белән очрашуга әзерләү генә әле.

Җиде мендәр

Кыш бабайның яраннары унике бүлмә аша уздырганнан соң, үзебезне иң дулкынландыргыч мизгелгә килеп җиттек дип санадык. Бу – Кыш бабайның Россия генә түгел, дөнья балаларыннан килгән хатларны укый торган кабинеты. Бабакайның кышкы туннарын, җәйге күлмәкләрен саклый торган гардероб бүлмәсе дә бик кызыклы. Нинди җәйге күлмәк, дисезме? Бәлки хәтерлисездер: Сочида узган җәйге Олимпиадада күлмәкчән йөргән иде бит ул. Кыскасы, бабай түгел, кәттә егет бу. Аның урын-җире дә кешенеке төсле түгел: печән тутырылган түшәктә йоклый. Ә мендәрләре атнадагы көннәр санынча – җидәү.

Кызыл тунын киеп, кулына ялтыравыклы таяк тоткан озын буйлы, төз гәүдәле Кыш бабайны балалар кул чабып каршы ала. Ул исә кунакларның һәрберсе белән күрешергә кул суза, хәл-әхвәл сораша.

Бөек шул инде

Кыш бабай биләмәсендәге почта әрҗәсе турында сөйләмәсәк, балаларның ни өчен тылсым көченә ышануын аңлап җиткермәс идек. Шәфкатьле бабакайга 2001 елдан алып илебезнең төрле почмакларыннан миллионлаган хат килгән. Үзебезнекеләр генә түгел, Кытай, Шри-Ланка, Австралия һәм бик күп Европа илләренең сабыйлары тормыш-көнкүрешләре турында сөйләгән, үз гозерләрен җиткергән аңа.

Великий Устюг юкка гына бөек түгел шул инде. Мондагы могҗизаларны тамаша кылган көннәр төш кебек үтә дә китә. Бер генә сәгать тә бушка узмады: борынгы һөнәрләр – тимердән, агачтан, хәтта боздан фигуралар ясау хикмәте белән таныштык. Үзебез дә чүкедек. Чыршы уенчыклары ясау техникасын өйрәндек, Яңа ел алдыннан, Европадагы кебек, ишеккә элеп кую өчен таҗ-венок та ясап карадык. Боз тауларыннан шуа-шуа хәлләр бетте. Әйтерсең үзебез балага әйләндек. Дөрес, бу хәлләрнең барысы да узган ел булды. Быел да барырга исәп бар.

Инде Кыш бабайга тизрәк хат та язасыгыз килгәндер. Анысының да билгеле бер көне тәгаенләнгән: 4 декабрь көнне күп кенә илләрнең почталарында, шул исәптән бездә дә Кыш бабайга язылган хатларны кабул итә башлыйлар.

Гүзәл ӘХМӘТҖАНОВА

Хәтер

Әлфия ападан өйрәнергә кирәк

tatar-congress.org

Башкалабыздагы Актерлар йортында күренекле җырчы, композитор Сара Садыйкованың туган көне уңаеннан кичә үткәрелде. Бер уңайдан «Сара Садыйкова – халык иҗатында» дип аталган яңа китапны тәкъдим итү дә булды. Авторы – кызы Әлфия апа Айдарская. Кичәне дә ул үзе әзерләде. Концертта Сара апа җырлары фонограммасыз башкарылды, фортепиано, баян тавышы гына яңгырады. Әнисенең җырларына әнә шулай сак, ихтирам белән карый Әлфия апа. Затлы җырларны затлы җырчылар гына җырларга тиеш, дип саный.

«Тормышта иң куркыныч әйбер – ялгызлык, әти-әниемнең хатирәләрен барлау миңа яшәргә көч бирә», – дип, еш кабатлый ул. Тамашачылар арасында да: «Әти-әниләребезне хөрмәтләргә Әлфияападан өйрәнергә кирәк. 97 яшендә дә якын кешеләре өчен өзелеп яши», – дигән фикерләр яңгырады. Аның эшләрен, чыннан да, санап кына бетерерлек түгел. Казанда гынамы, ел саен яңа программа төзеп, Мәскәүдәге Әсәдуллаев йортында да имтихан тота ул. Шул арада әби-бабаларының, әтисенең туган яклары – Яшел Үзән районындагы Айдар авылына, Апас районындагы Тутай авылына кайтырга да өлгерә. Бу авылларда аның көче белән музейлар эшләп тора. Соңгы елларда гына Әлфия апа әти-әнисе истәлегенә берничә китап чыгарды. Алар арасында «Бибисара моңнары», «Ил кызы», «Ак калфак», «Җидегән чишмә», «Идел суы ага торыр» дигәннәре бар. Ә монысында – «Сара Садыйкова – халык иҗатында» дигәнендә – ул беренче өлештә әнисенә багышланган шигырьләрне туплаган. «Шигъри моңга бай татар халкы, үзенең җырчы сандугачына багышлап, бик күп шигырь язды, әле дә яза. Шул рәвешчә аңа булган чиксез мәхәббәтен, соклану һәм рәхмәтен белдерә», – дип шатлана. Китапка кергән шигырьләр арасында Гөлшат Зәйнашева, Гамил Афзал, Мөдәррис Әгъләмов кебек олпат шагыйрьләребезнеке дә, каләм тибрәтергә яраткан халкыбыз язганнары да бар. Икенче өлештә исә Сара апаның үз шигырьләре урын алган. Әйе-әйе, татар сандугачы җырлап, көйләр язып кына калмаган, үзе дә шигырьләр иҗат иткән. Тик алар, үзем өчен генә диптер инде, анда-монда сибелеп калган. Әлфия апа аларны күп еллар буена берәмтекләп җыйнап, китап итеп чыгару дәрәҗәсенә җиткергән.

Татар халкы мәшһүр җырчысы Сара апа Садыйкованы үзе исән чакта ук «Татар сандугачы» дип атап йөртте. «Әнием бу шигъри исемне гомеренең соңгы көннәренәчә горур саклады. Аның тормышында бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып торган тамашачы мәхәббәте бар иде», – ди ул. Бу җәһәттән әнисенең тамашачы белән аралашкан соңгы көннәрен дә искә алды:

– 1986 ел. Апрель. Татар сәхнәсендә кабатланмас могҗиза – вафатына фәкать бер генә ай калган Сара Садыйкова сәхнәгә чыга. Тамашачы аның хәлен аңлый, чөнки сәхнәдә чак-чак кына басып торган җырчы-композиторның тавышы сүнеп барган чишмә моңына тәңгәл. «Идел суы»ның бер генә куплетын җырларга җитте аның тыны. Әмма могҗиза булды: күренмәгән, ишетелмәгән фәрманга буйсынгандай, бер мизгелдә зал аягүрә басты да алкышлый башлады. Бу аның моң канатларына көч бирде һәм әнием Мансур Мозаффаровның «Сайра, сандугач»ын шундый итеп башкарды, әйтерсең аның һәр авазын күкләр дә, җаннар да үзенә кабул итеп торды. Ул, бөтен залны кочагына алырга теләгәндәй, кулларын киң итеп җәйде дә: «Кадерле тамашачыларым, мин сезне бик яратам, шуңа күрә каршыгызга килдем!» – диде. Сәхнә читендә басып торган килеш, бу күренештән мин яшьсез еладым…

Сара апа: «Җырлаучысы булса, җыр мәңгелек», – дип әйтергә яраткан. Әйтерсең лә бу сүзләр белән ул үзенә һәйкәл салып калдырган. Концертта кырыгынчы еллардан алып сиксәненче елларга кадәр язылган җырлар яңгырады. Һәм ни гаҗәп: алар барысы да хәзерге көнгәчә популяр булып кала бирә. Әлфия апа архивтан әле бер тапкыр да башкарылмаган җыр ноталарын да эзләп тапкан. Тамашачы яңаларын да бик мөкиббән китеп тыңлады, аларга озын гомер юрады.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

Энциклопедия – иң зур һәйкәл

Буа районы турында яңа энциклопедия дөнья күрде. Китапны «Татар-информ» матбугат агентлыгында журналистлар белән очрашуда тәкъдим иттеләр.

Буа якташлыгы идарә рәисе Ирек Закиров Буа турында беренче энциклопедиянең 2010 елда чыкканын искәртте. Ул 3000 тираж белән басылып чыккан булса, яңа энциклопедиянең тиражы – 2500.

– Еллар узды, төрле вакыйгалар булды, яңа шәхесләр, мәгълүматлар барлыкка килде. Берничә ел элек энциклопедияне яңартырга кирәк дигән фикергә килдек. Якташлык җәмгыяте генә мондый эшне башкарып чыга алмый иде. Район оешмаларына, Татар энциклопедиясе институтына мөрәҗәгать иттек, – диде Ирек Закиров. – Ел ярымда бу эшне башкарып чыгарбыз, дип уйлаган идек. Әмма энциклопедия белән эшләү бик гади булмады. Җаваплылык зур иде: һәрбер фактны, шәхесне җентекләп тикшереп, беренче басмада булган кайбер ялгышларны төзәтеп һәм аларны кабатламаска тырышып, басманы әзерләү ике ел ярымга сузылды. Мондый энциклопедия ел саен басылмый. Безнең төп максат сыйфат һәм дөреслек иде.

Татар энциклопедиясе институты директоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев әйтүенчә, Татарстанда өч район гына сыйфатлы энциклопедиясе белән горурлана ала. Бу – Спас районы һәм Болгар шәһәре, Чүпрәле, Буа районнары.

– Татарстанның 43 районы да энциклопедия чыгарса, республика өчен нинди зур байлык булыр иде. Районнар энциклопедиясен чыгару хыялым бар. Бу эшкә башкаларның да кушылуын теләр идек. Институтның тәҗрибәсе бай: коллектив инде чирек гасыр төрле энциклопедик басмалар төзү буенча эшли, – диде ул.

Буа якташлыгы идарә әгъзасы, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис фикеренчә, энциклопедия ул – иң зур һәйкәл.

– Миннән Татарстанда нинди зур казанышлар булганны сорасалар, иң беренче Татарстан үз энциклопедиясен, берничә томлы тарихын булдырды, дияр идем. Болардан да зур казаныш юк. Энциклопедия һәр кешенең өстәл китабы булырга тиеш. Ул белем генә биреп калмый, тәрбияли һәм яшәргә дә өйрәтә. Буа энциклопедиясенә кертелгән 2,5 мең кеше язмышының һәркайсын роман итеп язып була, – диде Ренат Харис.

Ләйсән САФИНА

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 ЯЗЫЛ!
2023 елның
беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2 КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

3 БҮЛӘККӘ
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

ЭШ СӨЙГӘННЕ ИЛ СӨЯР

Үрнәк

Тәвәккәл, фидакарь, үз эшләренең чын осталары булган янгын сүндерүчеләр Чаллыда яши. Шәһәрнең 55 нче янгын сүндерү бүлеге Россиядә иң яхшысы дип табылды. Алар «Иң яхшы янгын сүндерү-коткару бүлеге» конкурсында илнең 1200 шәһәреннән 4 меңнән артык янгын бүлеген узып, беренчелекне яулады.

chelny-izvest.ru

1981 елда эшли башлаган 55 нче янгын сүндерү бүлегендә бүген 95 кеше хезмәт куя. 55 нче янгын сүндерү-коткару отряды башлыгы Алмаз Мифтахетдинов әйтүенчә, иң яхшы бүлекне сайлап алуда оператив хезмәт эшчәнлеге күрсәткечләре, махсус җиһазлар һәм яңа янгын сүндерү технологияләре исәпкә алынган.

– Конкурс башта отряд бүлекчәләре арасында узды. Аннан республика дәрәҗәсенә, соңрак федераль округка үттек. Конкурсның бәяләү критерийлары күп: якынча 73 позиция. Һәрберсе буенча баллар җыела. Әйтик, Россия Федерациясе дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән хезмәткәрләр саны. Безнең бүлектә андыйлар – бишәү. Ведомство медальләре, янгын сүндерү, гадәттән тыш хәлләрне бетерү, экипажны коткару өчен медальләр дә исәпкә алынды, – дип сөйләде Алмаз Мифтахетдинов.

Отряд башлыгы әйтүенчә, һөнәри бәйгеләр янгын сүндерүчеләрнең әзерлеген һәм чыдамлыгын яхшырта.

– Безнең бүлек бу бәйгедә беренче тапкыр гына катнашмый. Быел ныклап әзерләндек, күрсәткечләребезне яхшырттык һәм ил күләмендә беренчелекне яуладык. Бу – команда эше, барыбызның да уртак хезмәт нәтиҗәсе. Монда һәр хезмәткәрнең ел дәвамындагы казанышлары исәпкә алына. Безнең хезмәткәрләр шәһәр күләмендәге төрле конкурсларда, спартакиадаларда, спорт ярышларында, шәһәрнең иҗтимагый тормышында актив катнаша, – ди Алмаз Мифтахетдинов. – Хезмәттә дә сынатмыйлар. Әйтик, иң куркынычы – Чаллыда газ шартлау, Минзәләдә самолет төшү фаҗигасендә янгын сүндерүдә катнаштылар.

Җитәкче сүзләренчә, махсус җиһазлар һәм ашыгыч коткару техникалары булу да мөһим.

– Бу – янгын сүндерү машиналары, мотоцикл, квадроциклллар. Һәр бүлек тә андый техника булу белән мактана алмый. Уку-матди база: мәйдан, бина, снарядлар, спорт җиһазлары да зур роль уйнагандыр, – диде ул.

Өлкән янгын сүндерүче Ранил Гаязов Чаллының 55 нче янгын сүндерү бүлегендә 2013 елдан бирле эшли.

– Безнең бүлек Чаллының иң яхшы бүлекләренең берсе санала. Коллективыбыз бердәм, ярдәмчел. Монда, әлбәттә, җитәкченең дә өлеше зур. Уку сәгатьләре, теория, физик дәресләр – эш көннәре режим буенча уза. Безнең бүлек зур, машиналар да күп. Аларның барысы да яхшы хәлдә, даими әзерлектә, – ди өлкән янгын сүндерүче.

Ранил Гаязов – республиканың иң яхшы янгын сүндерүчесе дә әле. Ул узган ел кросс-фит, штурм баскычы, каршылыклар полосасын узу кебек ярышларда үзенең яхшы физик әзерлеген күрсәткән һәм «Иң яхшы янгын сүндерүче» бәйгесендә җиңү яулаган.

– Әлеге һөнәри бәйгедә өченче ел рәттән катнашам, узган ел беренче урын алдым. Җиңәрмен дип уйламаган идем. Иң катлаулы сынау каршылыклар полосасы булды, көндәшләрем дә көчле иде. Тик минем алга максат куелган иде һәм мин аңа таба бардым. Минемчә, мондый ярышлар безгә физик яктан гына түгел, төрле авыр очракларга рухи яктан да әзер булуыбыз өчен кирәк, – ди Ранил. – Быел Татарстан буенча кросс-фитта хезмәттәшем белән икенче урын алдык. Хәзер федераль ярышларга әзерләнәбез. Сынауларда да, хезмәттә дә без бит үзебез генә эшләмибез, иң мөһиме – бердәм команда. Янгынга звено белән керәбез. Алда баручымы ул, арттамы, без аңа үзебезгә кебек ышанабыз. Янгынга ничә кеше керә, шуның кадәр үк чыгарга тиеш. Бер-береңә ярдәм итү һәм кешеләрне коткару – безнең эштә иң мөһиме.

Ранил фикеренчә, бәйгеләрдә яхшы күрсәткечләр дә – бердәм команда эше нәтиҗәсе.

– Коллектив ярдәм итмәсә, булмый да ул. Бер-беребезгә терәк булырга тырышабыз. Шундый ярдәм булганда шөгыльләнергә дә рәхәт, – ди янгын сүндерүче.

Ләйсән САФИНА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Антистереотип

Безнең белән Президент та, ваграк түрәләр дә, хәтта хатын (ир) галиҗәнапләре дә түгел, ә гади генә стереотиплар идарә итә. Без тирә-якка күз салабыз да чынбарлыкны түгел, үзебез күрергә теләгән нәрсәләрне дә түгел, ә стереотипларны күрәбез, шуларны ишетәбез...

Иң күп таралган стереотип – сары чәчле кызлар сантыйрак була. Бу, әлбәттә, дөрес түгел инде. Гомумән, чәч белән акылның бөтенләй бәйләнеше юк. Хиллари Клинтон, Кристиан Лагард, Ангела Меркель – моның якты мисалы. Дөрес түгел, әмма киң таралган. Шуңа күрә, сары чәчләрнең чынлап та сантыйлары, моңа ышанып, чәчен карага манып йөри. Андыйлар күп...

Хатын-кыз колагы белән ярата, диләр. Ә ир-ат йөрәгенә юл – ашказаны аша. Ә саңгырау хатын-кыз? Ярый... Менә сез йөргән кызыгызга гел матур сүзләр генә сөйләп торыгыз әле. Бернинди ресторанга, һич югы кафега да чакырмагыз. Яратамы ул моны? Шиш! Һәм дөрес эшли. Ну, колагына эленгән токмач белән туклана алмый бит инде ул. Хатының булса да шул. Син берни дә дәшмәскә мөмкинсең, әмма суыткычың тулы булырга тиеш. Гомумән, хатын-кыз йөрәгенә юл – суыткыч аша... Димәк, ашказаны аша. Ләкин бу бердәнбер юл түгел. Ачның ачуы яман, дигән сүз дә дөреслеккә туры килми. Ачның ачуын басар өчен, аны тукландыру да җитә. Ә менә тук кеше ачуланса... Монда инде нишләргә дә белеп булмый.

Стереотиплар гомер буе озата. Ул «тиеш»ләрнең чиге-чамасы юк.

Бала «бишле»гә укырга тиеш, диләр. Бала укырга тиеш. «Бишле»гә укуы аның башлырак, акыллырак булуын аңлатмый. Бу нибары аның йогынтыга тизрәк бирелүчән, ираклашучан икәнен генә аңлата. Иң өметлесе – «өчле»гә укыган бала. Димәк, ул алтын урталыкны таба белә: балачакның да рәхәтен күрә, укуын да бөтенләй үк онытмый. Белем запасын соңыннан да тулыландырырга мөмкин, ә балачакны кире кайтарып булмый. Сабый чагында балалык рәхәтен күреп туймаган кеше гомер буена балалыктан арына алмый.

Мәктәпне тәмамлагач, кеше югары белем алырга тиеш. Югары белем, кызыл диплом булу яхшы, әлбәттә. Ә бүген иң киң таралган һөнәрләр – сатучы, каравылчы, таксист... Моның өчен диплом мотлак түгел. Ләкин кызыл диплом да кешенең яхшы белгеч яки акыллы кеше икәнен билгеләми. Ул бары тик: «Бу кеше бер катыргы өчен үзенең яшьлеген корбан итәргә сәләтле», – дигәнне генә аңлата. Диагнозның бер төре, кыскасы.

Кеше эшләргә тиеш. Монысы – стереотипларның иң коточкычы. Әгәр эшлисе килми икән, теләге юк икән – кеше беркайда да эшләргә тиеш түгел. Теләге булганнар гына эшләсен. Эшлисе килмәгәннәргә пособие билгеләргә кирәк. Чөнки теләмәгән килеш кайдадыр эшләп йөргән кешедән дә куркынычрак зат юк. Менә күз алдына китерегез. Табиб. Хирург. Аның бу хастаханәдә бер минут та эшлисе килми. Һәм ул сезгә операция ясарга тиеш... Ә кемнеңдер бик эшлисе килә, тик алмыйлар – буш урын юк: аның урынында теге хирург эшли...

Эшләгән өчен акча түләргә кирәк. Безнең илдә бу стереотип акрынлап юкка чыгып килә – акча түләргә бик ашыкмыйлар. Җитәкчеләребез түбәндәге мантыйк буенча гамәл кыла. «Эшләгән өчен акча түләргә? Кирәкми! Бушка эшләргә дә риза түгел икән, димәк, ул үз һөнәрен яратмый. Мондый кешедән беркайчан да рәт чыкмаячак, аны эш нәтиҗәсе түгел, ә акча гына кызыксындыра. Әгәр кеше үз һөнәрен ярата икән, ул бушка эшләргә дә әзер. Бушка эшләргә дә риза икән, ник аңа акча түләргә?»

Кеше гаилә корырга тиеш. Бала тудырырга... Билгеле бер яшькә җиту белән кешене: «Кайчан өйләнәсең инде?», «Кайчан кияүгә чыгасың?» – дип аптырата башлыйлар. Хәтта ул бик булдыксыз, юньсез кеше булса да шулай диләр. Хәтта әти-әнисе шулай ди. «Балам, гаилә кора күрмә, кемнедер бәхетсез итәсең бит», – диюче юк. Ана – бөек исем... Ә ул аналарның кайберсе бары тик абортка соңлаган өчен генә бөек булып йөри. Бөеклекләре, прәме, һәйкәл куярлык. Олы кеше акыллы һәм тәҗрибәле була. Ә тәҗрибә – сантыйлык нәтиҗәсе.

Һәм сез мине дә стереотип буенча кабул итәсез. Ахырда җилле генә бер мәгънә чыгарып куюымны көтәсез. Ләкин мәгънәсез язмалар да була. Бу – нәкъ шул очрак, чөнки стереотипларга кизәнүдән дә мәгънәсезрәк нәрсә юк.

Спорт

ВӘГЪДӘНЕ КЕМ ҮТӘР?

ЛЕОНИД СЛУЦКИЙ БЕРЕНЧЕ ЛИГАДА ЭШЛИ АЛМАДЫ

Көтелгән хәбәр көтелмәгән яктан килде. Спорт сөючеләр республиканың төп командасы – «Ак барс»та баш тренер алмашынасын фаразлаган арада «Рубин» Леонид Слуцкийның эштән китүен хәбәр итте. Нәтиҗә белән артык сөендермәсә дә, үзенә игътибарны туплый белгән остаз Казанның футбол командасын 1062 көн җитәкләде һәм, һичшиксез, клуб тарихына кереп калды. Моннан бер ай элек фанатлар Слуцкийны эштән җибәрүне сорап хат язган иде.

	Команда	уен	очко
1	Алания	18	35
2	Балтика	18	35
3	Енисей	18	31
4	Арсенал	18	31
5	**Рубин**	**18**	**31**
6	СКА-Хабаровск	18	29
7	КАМАЗ	18	27
8	Нефтехимик	18	27
9	Шинник	18	27
10	Волгарь	18	26
11	Динамо Мх	18	25
12	Акрон	18	20
13	Родина	18	20
14	Уфа	18	18
15	Велес	18	16
16	Кубань	18	16
17	Краснодар-2	18	12
18	Волга Ул	18	12

Леонид Слуцкийны Казан клубына 2019 елның 19 декабрендә эшкә алдылар. Тренер вазыйфасында ул Роман Шароновны алмаштырды: «Рубин» җитәкчелегенең тотрыксызлыктан арынып, танылган остаз белән яңа тарих язасы килде. Җитмәсә, заманында ЦСКА һәм Россия җыелма командасын җитәкләгән, чит илдә дә тәҗрибә туплап кайткан кеше. «Турнир таблицасында аскы өлештә урнашкан командага эшкә килгәнем юк иде. Әмма монысы да кызыклы тәҗрибә булачак. Минем өчен «Рубин» – Россия футболында әйдәп баручыларның берсе һәм бу шулай булачак та», – диде Леонид Слуцкий беренче эш көнендә.

rubin-kazan.ru

Беренче төп бурыч команданы премьер-лигада саклап калудан гыйбарәт иде. Слуцкий килгәндә 13 нче урында булган «Рубин» сезонны 10 нчы урында тәмамлады. Киләсе елда исә команда чемпионатта дүртенче урынны алды һәм Европа турнирында – Конференцияләр Кубогында чыгыш ясау хокукына ия булды. Казан клубында тормыш күзгә күренеп үзгәрде. Команда уенны яхшырды, яңа футболчылар килде. Киләчәктә Европадагы иң яхшы яшь футболчыларның берсе булып танылачак Хвича Кварацхелия «Рубин»ның төп уенчыларыннан берсенә әверелде. Монысын Слуцкийның тырышлыгы дип бәяләделәр. Баш тренер үзе исә футбол белән генә чикләнмәде. Журналистлар белән рәхәтләнеп аралашты, тапшыруларда катнашты, уенчылары белән җырбиюдә осталыгын күрсәтте. Сүзгә саранлыгы белән танылган Корбан Бәрдыевтан соң Казан клубы җәмәгатьчелек өчен иң ачык спорт оешмаларының берсенә әверелде.

«Рубин»да яңа Европа дәрәҗәсенә күтәрелү, шуның ярдәмендә акча эшләү турында хыялландылар. Әмма Конференцияләр Лигасында «Ракув»ка оттыру белән башланган сезон коточкыч нәтиҗәләр белән тәмамланды. 21 майда үз кырында Уфага җиңелеп, «Рубин» премьер-лигадан төшеп калды. Казан командасының иң көчлеләр сафыннан чыкканнан бирле мондый хәлгә дучар булганы юк иде. Төп сәбәбе – мәгълүм вакыйгалар аркасында чит ил уенчыларының Россиядән китеп баруы. Ә командада төп өстенлек нәкъ менә аларга бирелгән иде. Слуцкий яшереп тормады: калган уенчыларга өмет юк.

Казан клубында бу вакыйганы ялгыш түгел, язмыш дип кабул иттеләр. Леонид Слуцкий үз вазыйфасында калды, «Рубин»да беренче лиганың иң шәп командасын җыйдылар һәм киләсе елга премьер-лигага күтәрелергә вәгъдә иттеләр. Әмма очколар җиңел бирелмәде. Яңа состав берләшеп уйный башлаганчы вакыт кирәк иде. Башка командалар «Рубин»ны төп көндәше итеп күрде. Слуцкийның исә хөкемдарлар белән мөнәсәбәте яхшырмады.

Сезонның яртысы инде тәмамланды, ә «Рубин»ның дүртенче урыннан югары күтәрелә алганы юк. Үзеннән өстәрәк бер генә көндәшен дә ота алмады. Моннан бер ай элек команда Россия Кубогыннан төшеп калгач, җанатарлар баш тренерны вазыйфасыннан җибәрүне таләп итеп, мөрәҗәгать белән чыкты, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановтан игътибар сорадылар. Бу хәлләрдән соң «Рубин» 6 матчта чыгыш ясап, өчесен отты, тагын 3 очрашуда ничьяга уйнады. 12 очко начар түгел. Әмма узган якшәмбедә Казанда «Енисей» белән булган очрашу ахырында баш хөкемдар Артем Чистяков Леонид Слуцкийны уеннан куып чыгарды. Ике көн узгач, Казан клубында баш тренерның эшеннән китүен әйттеләр. Үз теләге белән.

«Рубин»ның матбугат хезмәте хәбәр итүенчә, Леоинд Слуцкий команда белән саубуллашканда җанатарларга, уенчыларга, клуб җитәкчелегенә, шәһәргә һәм республикага рәхмәт әйткән. Футбол клубы да аны рәхмәт сүзләре белән озата. Баш тренер вазыйфасына исә Юрий Уткульбаевны билгеләгәннәр. «Рубин»да уйнаган һәм яшь футболчылар белән эшләгән кеше. 53 яшьлек белгеч Чаллының «КАМАЗ» клубында спорт директоры, «Рубин-2» һәм Казахстанның «Актүбә» командаларының баш тренеры булды. 2016–2020 елларда «Нефтехимик»та эшләде, аннан соң «Рубин»да департамент җитәкчесе вазыйфасын башкарды. Елның соңгы ике матчында команда белән ул идарә итәчәк. Аннары ни булыр? Вәгъдәне үтисе бар бит.

Илнар ХӨСНУЛЛИН

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6697 данә
Гомуми тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 369

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+